**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ LII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР №82**

***Симәк авылы*** ***5 февраль 2025 ел.***

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә хакында «2020 елның «16» декабрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аеры закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-Ф номерлы Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципал районы прокурорының 2025 елның 22 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерл протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль район Симәк авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирле Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авы җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турынд Нигезләмә хакында «2020 елның «16» декабрендәге 7 номерлы карарына түбәндә үзгәрешне кертергә:

1.1. 13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин ит өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарынд билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин ит өчен товарлар, эшләр, сатып-алуларның план-графигы нигезендә төзелә (Росси Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелергә тиешле сать алу очракларыннан тыш), һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәлә лимитлары чикләрендә түләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренд Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халык җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районын Симәк авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мөслим районы
Симәк авыл җирлеге башлыгы: Садертдинов Р.Ә